# ,,Мин татарча сөйләшәм''

**2018-2019 уку елы.**
**МАОУ «СОШ №21»**

“Мин татарча сөйләшәм “ Республика күләм акцияне әзерләделәр:

***Елена Мухаметзяновна  Утябаева***

*Чаллы шәһәре, 21 нче мәктәбнең өстәмә белем бирү педагогы, “Чишмәкәй” берләшмәсе җитәкчесе.*

***Галиулина Альфира Харисовна***

*Химия укытучысы, 7б сыйныфының җитәкчесе.*






# Акция үткәрүнен бурычлары, максаты

***Акция укчыларның, яшьләрнең, шәһәр халкының татар телен куллану сферасын киңәйтү, туган як тарихы, мәдәнияте белән кызыксынуын арттыру, толерантлылык тәрбияләү максатыннан үткәрелә***

# Укучылар”Мин татарча сөйләшәм” акциясен башларга әзерләнәләр.



# Без әзер халык белән сөйләшергә…











ОГЭ-2019
ГЕОГРАФИЯ

# Сүзлек






***Балалар истәлек өчен, аралашкан кешеләргә, сүзлекләр тараттылар.***





Хәлләр ничек?
хат
письмо
он, она, оно
укый
это
бу
яблоко
алма
язык
тел

# Татарча сөйләшәбез, елмаюлар өләшәбез.

















татарча сөйләшәм!
Мин татарча сөйләшәм!
Сузлек
(Словарь).

Яр Чаллы мәгариф идәрәсе муниципаль автономияле балаларга өстәмә белем бирү оешмасы
“15 нче санлы балалар иҗат йорты” милли мәдәният бүлеге
**“Мин татарча сөйләшәм”**
республика күләм акция нигезләмәсе буенча:




***Яр Чаллы шәһәренең 3яб бистәсенең “Чишмәкәй” берләшмәсенә йөрүче 21 нче мәктәпнең 7б сыйныфы укучылары, язгы каникулларның беренче көнендә, 27.03.19 Яр Чаллы шәһәренең “Fresco” кибете янында өлкәннәр белән татарча сөйләшеп “ Тел -бетмәс хәзинә” темасы астында, республика күләм акция кысаларында катнаштылар*.**


ВНИМАНИЕ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
«СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА № 21»


ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕНЕҢ
«21нче УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ»
МУНИЦИПАЛЬ АВТОНОМИЯЛЕ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ




ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕНЕҢ
«21нче УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ»
МУНИЦИПАЛЬ АВТОНОМИЯЛЕ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# *Мактәп яныннан Тимерьюлчылар урамы буйлап «Fresco» кибетенә юнәлдек*




Fresco
продуктовый бутик


АПТЕКА
ДАРУХАНӘ
8-21
АРЕНДА




# Юл унаенда 2нче номерлы музыкал мәктәпкә дә тукталдык.



# Әкият иленә дә кереп чыктык.



# *Мактәп яныннан Тимерьюлчылар урамы буйлап «Чаллы Икмәге» кибетенә юнәлдек*








# *Йөзебез алсу, куңелләр күтәренке.*





# “Чаллы Икмәге “ кибете янына килеп тә җиттек.












# Сөйләшик әле дуслар!

**Фәния апа белән аралашу балаларга бик охшады.**







# Татар теле туган тел, безгә якын булган тел .









# Әйдә дуслар сөйләшик, туган телдә серләшик.

МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!





***Бераз гына туңсак та , сер бирмәдек салкынга.***

***Сөйләштек без аңлаштык, татар теле хакында.***

МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!






*Татар теле укытучысы Дания Гарифулловна да безнен белән катнашты.*



# Рәзилә Яббаровна да ризалашты безнен белән эшләп китәргә




АНАЛИЗ ҮРНӘКЛӘРЕ
Ә син татарча сөйләшәсеңме?
Әйдә татарча сөйләшик!

# Безнең нәтиҗә






# Безнең нәтиҗә







Управление образования и по делам молодежи
города Набережные Челны
Муниципальное автономное учреждение
дополнительного образования
«Дом детского творчества №15»
Диплом
"Халык әйтсә – хак әйтә!"
бәйгесе
"Мин татарча сөйләшәм!"
шәһәр программасы
1 нче этап
III - дәрәҗә
№ 21 нче мәктәп командасы
(Җитәкчесе: Утябаева Е.М.)
№ 15 нче Балалар иҗат йорты"
иректоры
С.Н. Грачева
24-26 окябрь 2018 ел
мин татарча сөйләшәм
г. Набережные Челны
2018 год


Муниципальное автономное учреждение
дополнительного образования
«Дом детского творчества №15»
Грамота
"Туган шәһәрем – Яр Чаллы"
бәйгесе
"Мин татарча сөйләшәм!"
шәһәр программасы
2 нче этап
II - урын
№ 21 нче мәктәп "Чишмәкәй" командасы
(Җитәкчеләре: Утябаева Е.М., Галиуллина Ә.Х., Вәлирахманова Д.Г.)
№ 15 нче Балалар иҗат йорты"
иректоры
С.Н. Граче
12-14 декабрь 201
мин татарча сөйләшәм



# Рәхмәт хаты

*Татарстан Республикасы*
*Яр Чаллы шәһәре мәгариф һәм яшьләр*
*белән эшләү идарәсе*
*Муниципаль автономияле өстәмә белем бирү оешмасы*
*"15 нче санлы Балалар иҗат йорты"*

**Хөрмәтле Елена Мөхәммәтҗан кызы Утябаева**
**һәм № 21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе**
**администрациясе!**


Сезгә *"Мин татарча сөйләшәм"* республикакүләм акциясендә актив катнашып, татар телен, халкыбызның милли гореф – гадәтләрен саклап калуда зур өлеш керткән өчен рәхмәт белдерәбез.

Эшегездә уңышлар, саулык – сәламәтлек телибез.

**Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе җитәкчесе** — **В.Х.Харисов**

**Муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе «15 нче санлы Балалар иҗат йорты" директоры** — **С.Н.Грачева**

**Яр Чаллы 2018 ел**



# ДИПЛОМ


*Яр Чаллы шәһәре*
*Башкарма комитеты мәгариф һәм*
*яшьләр белән эшләү идарәсе*
*Муниципаль автономияле*
*өстәмә белем бирү оешмасы*
*"15 нче санлы Балалар иҗат йорты"*

***"Мин татарча сөйләшәм!"***
***республикакүләм акциясендә***
**II - дәрәҗә**

**№ 21 нче мәктәп командасы**
**(Җитәкчеләре: Утябаева Е.М., Галиуллина Ә.Х.)**

**"№ 15 нче Балалар иҗат йорты" директоры** — **С.Н. Грачева**

**10 апрель 2018 ел**



муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе
15 НЧЕ БАЛАЛАР ИҖАТ ЙОРТЫ

муниципальное автономное учреждение дополнительного образования
ДОМ ДЕТСКОГО ТВОРЧЕСТВА № 15

# ГРАМОТА

*“Иң татлы тел – туган тел”*
*шәһәркүләм нәфис сүз остасы бәйгесе*

**I - урын**
**№ 21 нче мәктәп “Чишмәкәй” берләшмәсе**
***“Кәҗә белән сарык” әкиятен сәхнәләштерү***
**(җитәкчеләре: Утябаева Е.М.,Нургалиева Ә.В.)**

Комсомол районы хакимияте башлыгы — А.И. Кислов

“№ 15 нче Балалар иҗат йорты” директоры — С.Н. Грачева

11 апрель 2018 ел

Иң татлы тел – туган тел

г. Набережные Челны
2018 год


мин татарча сөйләшәм!


мин татарча сөйләшәм!









# Без татарча сөйләшәбез



**Инде шактый еллар Чаллыда һәм республикабыз күләмендә «Мин татарча сөйләшәм» акциясе уңышлы гына тормышка ашырылып килә. Бу чарада шәһәрнең 21 нче мәктәбе дә читтә калмый.**

Һәр этабында балаларны «Чишмәкәй» түгәрәге җитәкчесе, естәмә белем бирү укытучысы Елена Утябаева әзерли. Барлык этаплар өчен дә исә Фирая Вәлиева җаваплы. Сыйныф житәкчеләре Альфира Галиулина, Дания Валирахманова, Разиля Фахрутдинова да акциядә актив катнаша. Әлбәттә инде, әлеге чараны укучылардан башка да күз алдына китереп булмый. Алар һәр тәкъдимне күтәреп алып, шундук үтәргә әзер торалар. Айсылу Алиакберова, Ильмир Галиуллин, Камилә Маннанова, Булат Хатипов – әнә шундыйлар. Без әлеге укучыларның үзләре белән дә сөйләштек.

**-Әлеге акциядә кайчаннан бирле катнашасыз?**

- «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә без инде 1 класстан алып катнашабыз, быел 7 ел була. Үз телебездә сөйләшеп, үз телебездә шундый чаралар үткәрү безгә бик ошый. Һәр этапларында теләп катнашабыз, урыннар алабыз.

**-Акция кысаларында нинди чаралар үткәрәсез?**

- Иң беренче чиратта, сәүдә үзәкләренә, җәмәгать урыннары-на чыгып, шәһәрдәшләребез белән татарча сөйләшәбез. Безнең тырышлыгыбызның нәтиҗәсе дә озак көттерми, дәрәҗәле урын-нарга ирешәбез. "Халык әйтсә, хак әйтә" дигән тема астында үтү-е ярышта беренче урын алдык. Шулай ук, "Туган шәһәребез Яр Чаллы" дигән конкурста катнаштык. Анда татар телендә шәһә-ребез тарихын, истәлекле урыннарын, символикасын, танылган шәхесләрен белүбезне исбатладык.

**- Ничек уйлыйсыз, татар телен үстерү өчен нәрсә эшләргә кирәк?**

- Иң мөһиме – татарча сөйләшергә, бер-беребез белән татар телендә аралашырга кирәк. Мәктәптә татар телен тагын да яхшырак итеп өйрәнү өчен "Кара – каршы сөйләшү", шигырь конкурслары оештырабыз. Үз телебездә татарча матур шигырьләр сөйләп, башкаларга да яхшы үрнәк күрсәтәбез. Шулай ук, татарча спектакльләр куябыз, аны балалар бакчаларына барып күрсәтәбез.

**– "Мин татарча сөйләшәм" акциясендә катнашырга дусларыгызны да чакырасызмы?**

- Әлбәттә, чөнки бу акциядә катнашу үзебезгә дә бик охшый. Әгәр дә шундый акцияләр күбрәк булса, һәм күбрәк кешеләр катнашса бик яхшы булыр иде. Шуңа күрә, без дусларыбызны да бу акциядә катнашырга чакырабыз.

Эльвира ГАЙНЕТДИНОВ

Гомер

Яңа Зе теты (Шо дип сань налы та Йөрәк-к куркынı көн сае щевые ча, хат файд булу гел. чатк зур г), кир



# Шәһри Чаллы

Җомга 23 март

2018 ел №20 (4488)

www.shahrichalli.ru

1990 елдан нәшер ителә

*Иҗтимагый-сәяси гомумшәһәр газетасы*

...яшьләр форумнарында, «Сәләт» яшьләр оешмасының төрле проектларында катнаша идем. Әле бүгенге көндә дә «Студентлар лигасы»нын «Транспортный Грант» исемле проекты оештыручыларының берсе мин.

Бәйләү исә минем хобби. Кечкенә чагымда әбиемнең үз кулы белән бәйләгән ашъяулыкларына, шалларга, тастымалларга гел соклана идем. Аның бәйләгәнен игътибар белән күзәтеп, үземә күрә өйрәнергә тырыша идем. Шулай итеп, 12-13 яшьтә үзем ыргак белән бәйләргә өйрәнә башладым һәм хәзерге көндә дә ыргак гел кулымнан төшми.

***– Бәйләүдән башка тагын берәр кул эшләре белән шөгыльләнәсеңме?***

— Мин, гомумән, тик утыра алмыйм, миңа һәрвакыт нәрсәдә булса эшләргә кирәк. Бер тапкыр матурлыкны күрү җитә, күңел кабат-кабат шул матурлыкка, яктылыкка тартыла башлый. Бәйләүдән тыш мин скрапбукинг, канзаши юнәлешләрен (ленталардан чәчәкләр) ясыйм, бисер белән дә бәйлим, бисердан кызлар өчен зәвыклы бизәнү әйберләре эшлим. Тегә генә белмим, ләкин өйрәнү теләгем бик зур.

Бүген бит интернет бар. Теләк бар икән, бөтен әйберне дә өйрәнергә була. Анда фоторәсемнәрдә генә күрсәтеп калмыйлар, ә видеоларда җентекләп өйрәтәләр, бик уңайлы.

***— Кемнән бирелгән сәләт бу?***

— Әйтканемчә, әбием дә, әнием дә бәйли. Без гаиләдә 3 туган, минем ике олы апам бар. Ләкин өчебездән бәйләү



...әйтүемчә товар сыйфатлы булырга тиеш.

***— Үзең күбрәк нәрсәләр бәйләргә яратасың?***

— Балалар өчен бик теләп бәйлим. Мәсәлән, апамның бәләкәчләренә комбинезоннар, кофталар, баш киемнәре, пинеткалар ясап бүләк иттем. Шулай ук, күлмәкләр бәйләргә яратам. Ул бит фантазияне дә эшкә җигә, бер күлмәк икенчесеннән аерылып торуын телисең, нинди-дер яңа бизәкләр өстисең. Гомумән, мин якыннарымны үземнең кул эшләре белән сөендерергә яратам.

***— Билгеле инде, бәйләү өчен тотылган җеп, энәләр һәм башка әйберләрнең дә бәяләре арзан түгел. Саткан очракта чыгымнар капланамы?***

— Әйе дөрестән дә, ул әйберләр берсе дә арзан түгел. Ләкин чыгымнар каплана. Шунысын да әйтәсем килә, башка кул эшләре белән шөгыльләнүчеләрне дә күзәтеп барам һәм аларның куйган югары бәяләренә шаккатам кайчакта. Мин алар белән чагыштырганда 2-3 тапкырга арзанрак куям. Арзан әйбер сыйфатсыз дигән сүз түгел әле. Гомумән, мин бит бәйли башлаганда да акча эшләү өчен түгел, ә күңелем таләп иткән өчен башладым.

***— Мастер-класслар үткәргәнең юкмы?***

— Моның турында уйлаган бар һәр бер генә тапкыр да түгел. Танышларым арасында да: "Өйрәт әле безне дә, безнең дә шулай бәйлисе килә", — дип сораучылар бар, ләкин һаман тәвәккәлләп булмый. Бәлки якын киләчәктә анысы да булыр.

***— Әңгәмәң өчен рәхмәт, Назилә.***

**Эльвира ГАЙНЕТДИНОВА**

## Без татарча сөйләшәбез!

**Туган телне үстерү һәр кешенең бурычы. Телебезгә мәхәббәт һәм ярату беренче чиратта гаиләдән килсә, икенче чиратта мәктәптә тәрбияләнә.**

Зяб бистәсенең 21 нче мәктәбе моңа дәлил булып тора. Анда «Чишмәкәй» түгәрәгенә йөрүче 6 "б" сыйныфы укучылары класс җитәкчеләре Альфира Галиулина һәм түгәрәк җитәкчеләре Елена Утябаева белән берлектә «Мин татарча сөйләшәм» республикакүләм акциясендә актив катнаштылар. Бу чара диалог-уен формасында барды. Укучылар бер-берсенә татарча сораулар бирделәр һәм җаваплар алдылар. Жюри аларның белемнәрен югары бәяләде.

«Чишмәкәй» түгәрәге мәктәптә күптәннән эшләп килә. Укучылар 2017-2018 уку елында «Мин татарча сөйләшәм» бәйгесенең һәр этабында актив катнаштылар. «Туган як турында» дип исемләнгән фестивальнең 2 нче этабында балалар икенче дәрәҗә диплом, ә татар халкы мәдәниятенә багышланган фестивальдә беренче дәрәҗә диплом алдылар.

«Мин татарча сөйләшәм» Республика күләм акциясенең җитәкчесе Фирая Вәлиева.

**Альфира ГАЛИУЛИНА**

# Һәр этапка әзербез ....











# *Безне оештыручы һәм әйдәп баручыбыз Фирая Раисовна Валеева.*





# “Туган шәһәрем - Яр Чаллы” этабына без әзер.





# 2018-2019 уку елында да “Шәһри Чаллы” газетасы безнең белән элемтәдә



...шушы тестлар белән очрашасың. Әмма С өлешендә үзеңнең индивидуаль белемнәреңне күрсәтә аласың. БДИга әзерлек вакытында алган белемнәр университеттагы дәресләрдәге җиремнәр белән кисешә. Имтиханнарга әзерлекнең файдасы булмыйча калмады.

*Ринат Вәлиәхмәтов, Яр Чаллы шәһәренең 8нче*

...белән мөнәсәбәтләр ничек? Әгәр боларның берәрсендә проблема була икән, бала имтиханнарга яхшылап әзерләнә алмаячак. Укудан кайткач, 4 сорауны да бирергә онытмагыз. Алар «Көнең ничек узды?», «Синең дусларыңның хәлләре ничек?», «Көн дәвамында синең белән нинди яхшы хәлләр булды?», «Сиңа минем ярдәмем кирәкме?».

**Алинә МИННЕВӘЛИЕВА**

мәктәпләрдә

## Театр – тәрбия чыганагы

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 132 ел тулу уңаеннан 21 нче мәктәпнең 6 “б” сыйныф укучылары игътибарына “Чишмәкәй” түгәрәгенә йөрүчеләр сәхнәләштергән “Кәҗә белән сарык” әкияте күрсәтелде.

Балаларның чын күңелләреннән бирелеп уйнаулары гамашачылар күңеленә барып җитте, чыгыш көчле алышларга күмелде. Әкият геройларына әйләнергә матур теп әзерләнгән костюмнар да ярдәм итте. Аларны балаарның әти-әниләре үз куллары белән теккән. Әкиятне әхнәләштергән 3 нче сыйныф укучыларына һәм балаарда туган телебезгә, мәдәнияткә кечкенәдән мәхәббәт әрбияләгәне өчен сыйныф җитәкчеләре А.Хәйдаровага әхмәтебезне белдерәбез.

**Әлфира ГАЛИУЛИНА,**
**21 нче мәктәп укытучысы**






Габдулла Тукай
БЕЗНЕ КЕШЕ ИТКӘН УКУ
КЕШЕНЕ АЛГА ИЛТКӘН УКУ
Сәгыйть Рәмиев
Муса Җәлил






Летопись славных
Календарь памятных




МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!
КИЛӘЧӘКНЕ ҮЗГӘРТӘМ!


мин татарча сөйләшәм!


мин татарча сөйләшәм!

# Рәхмәт сүзе

***Туган тел***

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле! Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Өлкәннәр сөенделәр , балаларга рахмәтләрен белдерделәр.

Балаларга өлкәннәр белән татар телендә аралашу да бик бик охшады.

# Презентацияне әзерләучеләр.






МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!
КИЛӘЧӘКНЕ ҮЗГӘРТӘМ!


мин татарча сөйләшәм!